# 6нчы сыйныфның татар төркемнәрендә

## алмашлык сүз төркемен кабатлау



- **«Кем тизрәк?» уены.**

Бирелгән сорау алмашлыкларыннан билгесезлек алмашлыклары ясап язарга.

*Кем, нәрсә, ни; нинди, кайсы; кайда, кая, кайдан, кайчан; ник, ничек; ничә, ничәнче, ничәләп.*

- *УЕН:* Я, КЕМ ӨЛГЕР?
- Уенга катнашучылар табышмакларның җавапларын табалар һәм очраган алмашлыкларны төркемчәләргә аерып язалар
- 1.Үзе шушында, үзе беленми, тынга беленә, күзгә күренми.
- 2.Аның эчен ашыйлар, тышын ташлыйлар.
- 3.Иснәми дә печәнне, капмый да ул саламны, үзе бара өстерәп күп төрәнле сабанны.
- 4. Бер анага мең бала, аларның да күлмәге кара, юсаң да агармый—шунысы бәла.

5. Алтын баш, камыш аяк, нечкә бил,-
Ни икәнен мин әйтмим, үзең бел!

6. Ал да гөл, үзе оча, аны бел.

7. Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак.

- ер йомгакта мең энә, сиңа тими, син тимә.
- 8.Дөньяда ике туган янәшә яши, берсен-берсе беркайчан да күрмиләр.
- 9. Үлчәүсез йөртелә, һәркемдә була. ,

10.Һәркемдә, бар. - "

11.Бер кыздан: «Бер көнне бакчада бер кеше белән йөридер идең. Ул нинди кеше иде?—дип сораганнар икән, кыз
аларга: "Аның анасы минем әнкәемнең каенанасы буладыр"; —
дип җавап бирде. Сораучылар: "Ул кеше белән бу кыз ничек
карендәш була икән?" -- дип тикшерә калдылар. Кыз үзләреннән
көлеп китте. Җавабын инде сез бирегез.

- Язма эшләр тикшерелә Һәм очколар бирелә. Табышмакларның җавапларын тапкан өчен дә очко бирергә мөмкин. Иң күп очко алган (команда) кеше җиңүче була..

# Табышмакларның җавабы.Алмашлыклар буенча белемегезне тикшерегез

1.Һава 2.Чикләвек 3.Трактор 4.Көнбагыш 5.Ашлык көлтәсе 6.Күбәләк 7.Куян 8.Керпе 9.Күзләр 10.Акыл 11.Әтисе.

Зат: аның, ул, аларның, мин, аны, аңа, сиңа, син, сез, минем

Тартым:

Күрсәтү: шушында, шунысы, бу, ул (искәрмәне искә төшерегез)

Сорау : ни, нинди, ничек

Билгеләү : үзе, бер,үзең,һәркемдә, үзләреннән

Билгесезлек: бер-берсен

Юклык: беркайчан

Барлыгы11+24(алмашлык)=35 очко

# Тест

- . Алмашлыклар нинди сүз төркемнә
  ренә карый?
- а) мөстәкыйль;
  ә) бәйлек;
- б) модаль. 1
- 2. Алмашлыкка туры килгән билгелә
  мәне күрсәтергә.
- а) эш яки хәлне белдерә;
- ә) предметның билгесен белдерә;
- б) исем, сыйфат, рәвеш, сан сүз төркемнә
  рен алмаштырып, аларның мәгънәләренә
  ишарә итә.
- 3. Җөмләдә алмашлыклар нинди функ
  ция үти?
- а) җөмлә кисәге булмый;
- ә) ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл булып киләләр;
- б) аергыч кына булып кала.
- 4. Алмашлыкларның ничә төркемчәсе
  бар?
- а) 2;
  ә) 7;
- б) 4.
- 5. Билгеләү алмашлыкларын күрсәтегез?
- а) минеке, аныкы, тегенеке;
- ә) һичкем, һичнәрсә, беркая;
- б) бары,һәркем,һәммә.
- 6. Бу алмашлыклар кайсы төркемчәгә
  карый: *теге, шул, тегеләй, болай?*
- а) күрсәтү алмашлыклары;
  ә) тартым алмашлыклары;
- б) зат алмашлыклары.

# Җавапларыгызны тикшерегез

- 1.Алмашлыклар нинди сүз төркемнә
ренә карый?
а) *мөстәкыйль;*
ә) бәйлек;
б) модаль.
2. Алмашлыкка туры килгән билгеләмәне күрсәтергә.
а) эш яки хәлне белдерә;
ә) предметның билгесен белдерә;
б) *исем, сыйфат, рәвеш, сан сүз төркемнә
рен алмаштырып, аларның мәгънәләренә
ишарә итә.*
3. Җөмләдә алмашлыклар нинди функ
ция үти?
а) җөмлә кисәге булмый;
ә) *ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл булып
киләләр;*
б) аергыч кына булып кала.
4. Алмашлыкларның ничә төркемчәсе
бар?
а) 2;
ә) *7;*
б) 4.